КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 2 октябрь г.Казань № 901

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Педагогик эшчәнлек төрен күздә тоткан югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирә торган мәгариф оешмалары студентларына стипендияләр рәвешендә айлык түләүләрне гамәлгә кую турында» 2016 ел, 20 сентябрь, 660 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Педагогик эшчәнлек төрен күздә тоткан югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирә торган мәгариф оешмалары студентларына стипендияләр рәвешендә айлык түләүләрне гамәлгә кую турында» 2016 ел, 20 сентябрь, 660 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 10 май, 338 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирә торган мәгариф оешмаларының педагогик эшчәнлек төрен күздә тоткан югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча укучы студентларына стипендияләр рәвешендә айлык түләүләр бирү кагыйдәләренә түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:

«$2^1$. Стипендияләр түләүгә каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүче – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба - Министрлык).»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирү мәгариф оешмалары студентларына эшчәнлекнең педагогик төрен күздә тота торган югары белем бирү мәгариф программалары буенча стипендияләр рәвешендә айлык түләүләрне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибендә:

3 пунктта «тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында каралган» сүзләрен «тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законында күрсәтелгән максатларга каралган» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункт өстәргә:

«$4^1$. Башка бюджетара трансфертларны бүлү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.»;

5 пунктта:

дүртенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең башка бюджетара трансфертлар хисабына башкарыла торган чыгымнарның юнәлешләрен билгели торган хокукый акт булу;

муниципаль берәмлек бюджетында Татарстан Республикасы бюджетыннан бирү планлаштырыла торган башка бюджетара трансфертларны үз эченә ала торган чараларны гамәлгә ашыруны финанс ягыннан тәэмин итү буенча муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре (җыелма бюджет язмасы) булу;

Министрлык белән башка бюджетара трансфертлар бирү турында төзелгән килешү булу.»;

түбәндәге эчтәлекле $5^1$ пункт өстәргә:

«$5^1$. Башка бюджетара трансфертлар сайлап алу критерийларына җавап бирә торган муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә:

муниципаль белем бирү оешмаларының педагогик кадрларга ихтыяҗы;

студент һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге башкарма комитеты арасында төзелгән укучы килешүләре булу.»;

түбәндәге эчтәлекле $5^2$ пункт өстәргә:

«$5^2$. Башка бюджетара трансфертлар бирүдән баш тарту өчен нигез булып тора:

әлеге Тәртипнең 6 пунктында каралган документларны тапшырмау (тапшыру тулы күләмдә түгел);

тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 5 һәм $5^1$ пунктлары белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве.»;

6 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә күчермәсе;»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең башка бюджетара трансфертлар исәбенә гамәлгә ашырыла торган чыгымнарның юнәлешен билгеле торган хокукый акт күчермәсе;

агымдагы финанс елына муниципаль берәмлек бюджеты турында (җыелма бюджет язмасы) муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карарыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан бирү планлаштырыла торган башка бюджетара трансфертларны үз эченә алган чаралар исемлеген гамәлгә ашыру буенча муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен үтәү өчен муниципаль берәмлек бюджетында бюджет ассигнованиеләре булуын раслый торган һәм вәкаләтле зат тарафыннан расланган өземтә.»;

8 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Килешүдә башка бюджетара трансфертларның күләме, аларның максатчан билгеләнеше, башка бюджетара трансфертларны бирүнең нәтиҗәлелек (нәтиҗәләре) күрсәткечләренең әһәмияте, башка бюджетара трансфертларны күчерү тәртибе, башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисап бирү сроклары һәм формалары, башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеге (нәтиҗәләре) күрсәткечләренә ирешү, килешүдә каралган башка бюджетара трансфертларны алучы тарафыннан үтәүне тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибе, килешү шартларын бозган өчен якларның җаваплылыгы карала.»;

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына бирелә торган башка бюджетара трансфертларның гомуми күләме (S) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S = \sum_{i=1}^{n} S_i,$$

монда:

$S_i$ – Татарстан Республикасы i- муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме;

n - башка бюджетара трансфертлар бирелә торган Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре саны.

i-муниципаль берәмлек бюджетына ($S_i$) бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S_i = m_{ij} \times 15\ 000,$$

монда:

$м_{ij}$ - i-муниципаль берәмлекнең j-нче студенты стипендия ала торган айлар саны;

15 000 - бер студентка стипендия түләүнең фиксацияләнгән күләме, сум.»;

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Министрлык, килешү төзелгәннән соң, эш көннәрендә исәпләнгән 15 көн эчендә, муниципаль берәмлек бюджеты акчалары белән операцияләрне исәпкә алу

өчен, Федераль казначылыкның территориаль органына Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениесендә ачылган шәхси счетына бүтән бюджетара трансферт күчерә.»;

11 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Башка бюджетара трансфертларны куллануның нәтиҗәлелеге (нәтиҗәләре) күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Башка бюджетара трансфертларны куллануның нәтиҗәлелеген бәяләү башка бюджетара трансфертларны куллануның нәтиҗәлелек күрсәткечләре нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Башкарма комитет, башка бюджетара трансферт бирелгән елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча, Министрлыкка кәгазьдә яисә башкарма комитет җитәкчесе яки аның вәкаләтле заты кул куйган электрон формада Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча башка бюджетара трансфертлар куллану һәм башка бюджетара трансфертлар куллану нәтиҗәлеге (нәтиҗәләре) күрсәткечләренә ирешү турында хисап тапшыра.

Әгәр муниципаль берәмлек тарафыннан башка бюджетара трансферт бирү елның 31 декабренә башка бюджетара трансферт бирү елыннан соң килүче елның 1 мартына кадәр муниципаль берәмлек бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле башка бюджетара трансфертларны куллануның нәтиҗәлелек күрсәткечләренә (нәтиҗәләренә) ирешелмәгән булса, башка бюджетара трансфертлар бирү елыннан соң килүче елның 1 мартына кадәр муниципаль берәмлек бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле башка бюджетара трансфертларның күләме ($V_{\text{кире кайтару}}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$V_{\text{кире кайтару}} = P \times D \times 0{,}1,$$

монда:

P – хисап финанс елында муниципаль берәмлек бюджетына бирелгән башка бюджетара трансферт күләме;

D - башка бюджетара трансфертны кире кайтару коэффициенты.

Муниципаль берәмлек бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле башка бюджетара трансфертлар күләмен хисап финанс елында муниципаль берәмлек бюджетына бирелгән башка бюджетара трансферт күләмендә исәпләгәндә башка бюджетара трансфертлар бирү елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына файдаланылмаган башка бюджетара трансферт күләме исәпкә алынмый.

Башка бюджетара трансфертны кире кайтару коэффициенты (D) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$D = 1 - \frac{T}{S},$$

монда:

T - ел ахырына башка бюджетара трансфертны файдалануның нәтиҗәлелек (нәтиҗә) күрсәткеченең фактта ирешелгән күрсәткече;

S - килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансфертны файдалануның нәтиҗәлелек (нәтиҗә) күрсәткеченең пландагы мәгънәсе.»;

14 пунктта «һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы» сүзләрен төшереп калдырырга;

15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Максатчан файдаланмаган һәм (яисә) бирү шартларын бозган очракта башка бюджетара трансфертлар Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты керемнә кире кайтарылырга тиеш.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин